**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

30 март 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге башлыгынын 20.03.2024 ел 1 нче номерлы «Сарман авыл җирлеге Яңа Әхмәт торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 19 октябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 19 октябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт авылында гражданнар җыены **карар итте:**

**1.** «Сарман авыл җирлеге Яңа Әхмәт торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 19 октябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 17 октябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарларына түбәндәге редакциядәге чаралар бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Яңа Әхмәт торак пунктында су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итүче инженерлык корылмалары төзү)

**2)** Һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары түгел (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре)) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Яңа Әхмәт торак пунктында һәйкәлне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары түгел (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре))

2. Җыен нәтиҗәләрен Сарман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлеге
Башлыгы ___________ Ф.М.Хөснуллин